Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы
Кощаково авыл җирлеге Советының
дүртенче чакырылышының бишенче утырышы

Кощаково авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ

29 декабрь, 2025 ел № 17

«Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2019 елның 28 октябрендәге 58 номерлы Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Кощаково авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлеге нигезендә Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Кощаково авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

«Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2019 елның 28 октябрендәге 58 номерлы Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Кощаково авыл җирлеге Советы карарына (2021 елның 18 мартындагы 23 номерлы, 2024 елның 25 октябрендәге 127 номерлы Совет карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1. 5 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

«5. Салым ташламасы салым салу объектларының түбәндәге төрләренә карата бирелә:

1) фатир, фатирның яисә бүлмәнең бер өлеше;

2) торак йорт яисә торак йортның бер өлеше;

3) гараж яисә машина урыны.

Салым ташламасы салым түләүчене сайлау буенча һәр төргә салым салуның бер объектына карата салым ташламалары куллану өчен нигезләрнең санына карамастан бирелә.

Салым ташламасы Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Кощаково авыл җирлеге территориясендә даими яшәүче (яшәү урыны буенча билгеләнгән тәртиптә теркәлгән) салым түләүчеләргә салым түләүче тарафыннан салым түләүче милкендәге һәм эшкуарлык эшчәнлегендә файдаланылмый торган салым салу объектына карата салым суммасы күләмендә салым түләүчеләргә бирелә.».

2. 2 пунктның 2.6 пунктчасына «, билгеләнешен проектлаучы күпфатирлы йорт булган төгәлләнмәгән төзелеш объектларыннан тыш» сүзләрен өстәргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районы рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

Кощаково авыл җирлеге башлыгы З.Н. Саттарова